ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЪ РАЙОНЫ
Д0БЪЯЗАВЫЛ
Ж:ИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422720, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Дебъяз авылы, Ленин ур, 28

СОВЕТ ДУБЪЯЗСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422720, Республика Татарстан, Высокогорский район
с. Дубъязы, ул. Ленина, 28

Тел./факс: +7(84365) 61-2-63, e-mail: Dub.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**2019 ел, 29 нчы июль** **№131**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы "Дебъяз авыл "'ирлеге" муниципаль берамлеге башкарма комитеты турында Нигезламане раслау турында**

"Россия Федерациясендэ ж:ирле узидарэ оештырунын: гомуми принциплары турында" 2003 ел, 6 нчы октябрь 131-ФЗ номерлы Федераль законнын: 37 нче статьясы, "Татарстан Республикасында жирле узидарэ турында" 2004 ел, 28 нче июнь, 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендэ, Дебъяз авьт ж:ирлеге башкарма комитетыньщ оештыру документларын гамэлдэге законнарга туры китеру максатында, "Дебъяз авыл ж:ирлеге" муниципаль берэмлеге Уставы белэн эш йертеп, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дебъяз авыл ж:ирлеге Советы,

**КАРАРИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дебъяз авьт ж:ирлеге Башкарма комитеты турында Нигезлэмэне расларга (теркэлгэн).

2. Дебъяз авыл ж:ирлеге Башкарма комитеты ж:итэкчесе 8.С.Низамовка Дебъяз авыл ж:ирлеге башкарма комитетынын. оештыру документларын Россия Федераль салым хезмэтенен: Татарстан Республикасы буенча 18 нче номерлы районара салым инспекциясендэ теркэуне тормышка ашырырга.

2. Уз кечен югалткан дип таныrга:

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дебъяз авыл ж:ирлеге Советынын: "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы "Дебъяз авьт ж:ирлеге" муниципаль берэмлеге Башкарма комитеты турында Нигезлэмэне раслау турында" 2018 ел, 13 нче февраль, 78 номерлы карарын.

3. 8леге карарны Биектау муниципаль районы рэсми сайтында Интернет челтэрендэ http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ hэм Татарстан Республикасынын. хокукый мэгълумат рэсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ бастырып халыкка ж:иткерергэ.

4. 8леге карарньщ утэлешен контрольдэ тотуны уз естемдэ калдырам.

Совет рэисе,
авыл ж:ирлеге Башлыгы о.С. Низамов

Кушымта

Расланган

ТР Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлеге Советы карары белән

29 июль 2019 № 131

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлеге башкарма комитеты турында НИГЕЗЛӘМӘ**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Дөбъяз авыл җирлеге башкарма комитеты (алга таба – җирлек Башкарма комитеты) «Дөбъяз авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең, "Дөбъяз авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы белән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләре һәм Федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары тарафыннан җирле үзидарә органнарына бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен башкару-оештыру органы булып тора. Җирлек башкарма комитеты федераль һәм республика законнары нигезендә оештырылган.

1.2. Тулы исеме – Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлеге Башкарма комитеты. Кыскача исеме – Дөбъяз авыл җирлеге Башкарма комитеты.

1.3. Башкарма комитетның оештыру-хокукый формасы: учреждение.

Җирлекнең Башкарма комитеты муниципаль казна учреждениесе булып санала.

1.4. Җирлек Башкарма комитеты юридик зат булып санала һәм үз исеменнән мөлкәти һәм шәхси мөлкәти булмаган хокуклар алырга һәм тормышка ашырырга, йөкләмәләр йөртергә, судта дәгъвачы һәм җавапчы була ала.

1.5. Җирлек Башкарма комитеты эшчәнлек сроклары чикләүләреннән башка оештырыла.

1.6. Җирлек Башкарма комитетының оештыру документы булып әлеге Нигезләмә санала.

1.7. Җирлек Башкарма комитеты Нигезләмәсенә һәм аңа барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү Дөбъяз авыл җирлеге Советы тарафыннан раслана.

1.8. Җирлек Башкарма комитетының аның тулы исемен үз эченә алган түгәрәк мөһере бар. Җирлек Башкарма комитетында үзенең исеме белән штамплар һәм бланклар, үзенең эмблемасы була ала.

1.9. Җирлек Башкарма комитеты эшчәнлеген финанс яктан тәэмин итү Дөбъяз авыл җирлеге бюджеты чаралары хисабына, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнарына, муниципаль хокукый актларга туры китереп, бюджет сметасы нигезендә тормышка ашырыла.

1.10. Җирлек Башкарма комитеты гамәлдәге законнар нигезендә аңа керүче чаралар белән операцияләрне, Федераль казначылык бүлекләрендә Россия

Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә аңа ачыла торган шәхси исәп-хисап счетлары аша тормышка ашыра.

1.11. Җирлек Башкарма комитеты үзенең йөкләмәләре буенча анык булган барлык мөлкәте белән җавап бирә.

1.12. Җирлек Башкарма комитеты юридик зат булып санала һәм үз исеменнән мөлкәти һәм шәхси мөлкәти булмаган хокуклар ала һәм тормышка ашыра, йөкләмәләр йөртә, гамәлдәге Россия Федерациясе законнары нигезендә судта һәм арбитраж судта дәгъвачы һәм җавапчы буларак чыгыш ясый.

1.13. Урнашкан урыны (факттагы, юридик адрес) 422720, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Дөбъяз авылы, Ленин ур, 28 йорт.

Башкарма комитетның урнашкан урыны аның дәүләт теркәве узган урыны белән билгеләнә.

Почта адресы 422720, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Дөбъяз авылы, Ленин ур, 28 йорт.

1.14. Җирлек Башкарма комитеты ул дәүләт теркәве узган моменттан юридик зат хокукларын ала.

1.13. Авыл җирлеге Башкарма комитеты муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи инструкцияләре төп эшчәнлек буенча җирлек башкарма комитеты карары белән расланалар һәм җирлек Башлыгы тарафыннан имзаланалар.

## 2. Авыл җирлеге Башлыгы

2.1. Җирлек Башкарма комитеты белән җирлек Башлыгы бер генә кеше идарәсе принципларында идарә итә.

2.2. Җирлек Башлыгы җирлекнең югары вазыйфаи заты булып санала, әлеге Устав нигезендә җирлектәге җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне чишү буенча үз вәкаләтләре бирелә.

2.3. Җирлек Башлыгы 5 елга гомуми тигез һәм турыдан-туры сайлау хокукы нигезендә сайлауларда яшерен тавыш бирү юлы белән, законнар һәм әлеге Устав нигезендә сайлана.

2.4 Җирлек башлыгы вәкаләтләре вазыйфага керешкән көннән башланып, яңа сайланган  җирлек башлыгы вазыйфаларына керешкәнчегә кадәр дәвам итә.

2.5. Авыл җирлеге башлыгы эшчәнлеген матди-финанс тәэмин итү авыл җирлеге бюджеты чаралары хисабына, федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм авыл җирлеге Уставы һәм норматив хокукый актларында каралган шартларда тормышка ашырыла.

2.6. Авыл җирлеге Башлыгы җирлек халкы һәм Советы контроле астында турыдан-туры хисап тота.

2.7. Авыл җирлеге Башлыгы авыл җирлеге Башкарма комитетын формалаштыра һәм аның эшчәнлеге белән  Устав һәм авыл җирлеге Башкарма комитеты турында Нигезләмә нигезендә җитәкчелек итә, авыл җирлеге Башкарма комитеты хезмәткәрләрен вазыйфага билгели һәм ала.

2.8. Җирлек башлыгы вакытлыча үз вәкаләтләрен башкара алмаган очракта (авыру сәбәпле, кыска сроклы ял), аларны Җирлек башлыгы урынбасары, ул

булмаган очракта – авыл җирлегендә вазыйфаи җаваплылыкның бүленеше нигезендә, җирлекнең җирле үзидарә органының башка вазыйфаи заты башкара.

2.9. Вакытлыча авыл җирлеге башлыгы вазыйфаларын башкару вазыйфасы Дөбъяз авыл җирлеге башлыгы боерыкнамәсе нигезендә йөкләнелә.

2.10. Авыл җирлеге Башкарма комитеты исеменнән судка дәгъва гаризаларын имзалый.

2.11. Судта, арбитраж судта, шулай ук билгеле дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарында авыл җирлеге мәнфәгатьләрен кайгырту һәм саклау буенча чарарлар күрүне тәэмин итә.

2.12. Үзе билгеләгән вазыйфаи затларга карата кызыксындыру һәм дисциплинар җаваплылык чараларын күрә.

2.13. Җирлек башлыгы Җирлек Советына үзенең эшәнлеге, башкарма комитет эшчәнлеге турында, шул исәптән җирлек Советы тарфыннан куелган мәсьәләләрне чишү буенча да еллык хисап тапшыра.

2.14. Җирлек Башлыгы авыл җирлеге Башкарма комитетының үз вәкаләтләрен тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген тагын да арттыру максатыннан киңәшмә органнары оештырырга хокуклы, шул исәптән бюджет һәм бюджеттан тыш чараларны куллану буенча да.

2.15. Әлеге Нигезләмә һәм Устав арасында каршылыклар булган очракта, Устав нигезләмәләре кулланыла. Устав һәм төбәк яки федераль законнар белән каршылыклар булган очракта Татарстан Республикасы законнары һәм Россия Федерациясе законнары кулланыла.

2.16. Җирлек Башлыгы “Коррупциягә каршы тору турында” 2008 ел, 25 нче декабрь 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләр һәм тыюларны тотарга һәм күрсәтелгән вазыйфаларны башкарырга тиеш.

## 3. Авыл җирлеге Башкарма комитетының вәкаләтләре

3.1. Дөбъяз авыл җирлеге Башкарма комитеты Дөбъяз авыл җирлеге башлыгы җитәкчелегендә:

1) Дөбъяз авыл җирлеге бюджет проектын төзүне, Дөбъяз авыл җирлеге бюджетын үтәүне тәэмин итә, әлеге бюджетны Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә үтәлүен тормышка ашыра, Дөбъяз авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап төзүне тәэмин итә;

2) Россия Федерациясе законнары нигезендә җирле салымнар һәм Дөбъяз авыл җирлеге җыемнарын билгеләү, үзгәртү һәм юкка чыгару турында муниципаль хокукый акт проектларын эшләп чыгара;

3) Дөбъяз авыл җирлеге муниципаль милкендә булган мөлкәт белән идарә итү, куллану һәм эш итүне тормышка ашыра;

4) Дөбъяз авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чаралары белән тәэмин итә;

5) җирлекләрдә яшәүче халыкка элемтә хезмәте, җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү өчен шартлар тудыра;

6) Дөбъяз авыл җирлегендә яшәүче халыкка элемтә хезмәте, җәмәгать

туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү өчен шартлар тудыра;

7) Дөбъяз авыл җирлеге территориясендә физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спорт үсешенә шартлар тудыруны булдыра, Дөбъяз авыл җирлегендә рәсми рәвештә физик культура-сәламәтләндерү, спорт чаралары уздыруны оештыра;

8) авыл җирлегенең архив фондын формалаштыра;

9) Дөбъяз авыл җирлеге территториясен төзекләндерү буенча кагыйдәләрне әзерли, аларның үтәлешен контрольдә тота, билгеләнгән кагыйдәләр буенча Дөбъяз авыл җирлеге территориясен төзекләндерүне оештыра;

10) адресация объектларына адреслар бирә, адресларны үзгәртә, юкка чыгара, урам-юл челтәре элементларына исемнәр бирә (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, региональ яисә муниципальара әһәмияттәге, муниципаль районның җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларыннан тыш), Дөбъяз авыл җирлеге чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирә, мондый исемнәрне үзгәртә, юкка чыгара, дәүләт адрес реестрында мәгълүмат урнаштыра;

11) авыл хуҗалыгы җитештерүе үсешенә ярдәм итә, кече һәм урта эшмәкәрлекнең үсешенә шартлар тудыра;

12) Дөбъяз авыл җирлегендә балалар һәм яшүсмерләр белән эшләүгә юнәлдерелгән чаралар оештыра һәм тормышка ашыра;

13) җәмәгать тәртибен саклауда канашучы гражданнарга яисә аларның берләшмәләренә ярдәм күрсәтә, халык дружиналары эшчәнлеге өчен шартлар тудыра;

14) көнкүреш калдыклары һәм чүп-чар җыю (шул исәптән аерым җыю) һәм чыгару буенча эшчәнлектә катнаша;

15) ритуаль хезмәтләр күрсәтүне оештыра җирләү урыннарын карап тотуны тәэмин итә;

16) Дөбъяз авыл җирлеге чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, ташлындык суларны чыгаруны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыра;

17) җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге алып бара;

18) милләтара һәм динара килешүне ныгытуга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру, Дөбъяз авыл җирлеге территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятләрен саклау һәм үстерү өчен шартлар тудыра, мигрантларны социаль һәм мәдәни адаптацияләүне, милләтара (этник) конфликтлар профилактикасын оештыра;

19) Дөбъяз авыл җирлеге халкының массакүләм ялын оештыру өчен шартлар тудыру һәм халыкның массакүләм ял урыннарын төзекләндерү, гражданнарга гомуми кулланылыштагы су объектларына һәм аларның яр кыры полосаларына ирекле керүне тәэмин итә.

3.2. Дөбъяз авыл җирлеге Башкарма комитеты федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә Устав белән билгеләнгән башка вәкаләтләрне тормышка ашыра.

3.3. Авыл җирлеге Башкарма комитеты хокуклы:

1) җирлек музейларын оештырырга;

2) җирлектә нотариус булмаган очракта, законнар белән билгеләнгән тәртиптә, нотариаль гамәлләр башкарырга;

3) опека һәм попечительлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруда катнашырга;

4) җирлек территориясендә милли-мәдәни автономияләрнең хокукларын гамәлгә ашыруга бәйле эшчәнлекне тормышка ашыру өчен шартлар тудырырга;

5) Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни үсешенә һәм җирлек территориясендәге милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендәге гамәлләрне тормышка ашыруга ярдәм күрсәтергә;

6) җирлек территориясендә урнашкан муниципаль предприятие һәм учреждениеләрнең мобилизацион әзерлеге буенча чаралар оештыру һәм тәэмин итәргә;

7) муниципаль янгыннан саклау хезмәте оештырырга;

8) туризм үсешенә шартлар тудырырга;

9) кеше хокукларын яклау һәм мәҗбүри тоту урыннарындагы затларга булышлык итүне иҗтимагый контрольне тәэмин итүче иҗтимагый күзәтү комиссияләренә теләктәшлек белдерергә;

11) инвалидларның иҗтимагый берләшмәләренә, шулай ук “Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында” 1995 ел, 24 нче ноябрь 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә инвалидларның бөтенроссия иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан төзелгән оешмаларга ярдәм күрсәтергә;

12) торак законнары нигезендә, гражданнарга социаль куллану торак фондының торак йортларыннан найм шартнамәләре буенча муниципаль торак фондыннан торак йортлар тәкъдим итәргә;

13) җирлек территориясендә яшәүче караучысыз калган хайванарны карау һәм тоту буенча чараларны тормышка ашырырга;

14) “Россия Федерациясендә хокук бозулар профилактикасы системасы нигезләре” Федераль законы нигезендә, хокук бозулар өлкәсендә профилактика чаралары уздырырга;

15) инвалидлар, сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен физик культураны һәм спортны, адаптив физик культураны һәм адаптив спортны үстерүгә булышлык күрсәтергә;

16) “Кулланучылар хокукларын яклау турында” 1992 ел, 7 нче февраль 2300-1 номерлы Россия Федерациясе законында билгеләнгән кулланучыларның хокукларын яклау буенча чараларны тормышка ашыру.

3.4. Авыл җирлеге Башкарма комитеты җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, муниципаль хокукый актлар нигезендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен тормышка ашыруны тәэмин итә.

3.5. Авыл җирлеге Башкарма комитеты федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары тарафыннан җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру вәкаләтләрен тормышка ашыра.

Авыл җирлеге Башкарма комитеты федераль законнар, законнар белән билгеләнгән башка төр дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашырырга, шулай ук башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, дәүләт хакимияте органнары компетенциясенә карамаган һәм Россия Федерациясе бюджет системасы

тарафыннан бирелгән бюджетара трансфертлары, җирле бюджет керемнәре хисабына һәм өстәмә норматив түләнгән салымнардан кергән керемнәр хисабына федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән аларның компетенциясеннән чыгарылмаган башка төр мәсьәләләрне хәл итәргә хокуклы.

3.6. Җирлек Башкарма комитеты «Дөбъяз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты чараларының төп бүлүчесе булып тора һәм җирле бюджет чыгымнары ведомство классификациясе белән билгеләнгән бюджет чараларын ведомство карамагында булган бүлүчеләргә һәм җирле бюджет чараларын алучыларга бүлеп бирергә хокуклы.

Җирлек Башкарма комитеты:

- ведомство карамагында булган бюджет учреждениеләренең керем һәм чыгым сметаларын раслый;

- бюджет исемлеген төзи, бюджет йөкләмәләре лимитларын ведомство карамагында булган бюджет чараларын бүлүчеләргә һәм алучыларга бүлә һәм тиешле бюджет бүлеген башкара;

- бюджет чараларын максатчан куллану өлешендә бюджет чараларын алучыларның контролен, аларны вакытында кире кайтаруны, хисапны тәкъдим итүне, муниципаль хезмәт күрсәтү буенча йөкләмәләрне үтәүне тормышка ашыра;

- «Дөбъяз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милке хуҗалык карамагында яки оператив идарә итү хокукында бирелгән бюджет чараларын бүлүчеләр, бюджет учреждениеләре һәм башка бюджет чараларын алучылар, муниципаль унитар предприятиеләр тарафыннан бюджет чараларын куллануны контрольдә тотуны тормышка ашыра.

3.7. Җирлек Башкарма комитеты билгеле елга бюджет исемлеге нигезендә «Дөбъяз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты чараларын алучы булып тора.

Җирлек Башлыгы бюджет чараларын алучы буларак түбәндәгеләргә хокуклы:

- расланган бюджет исемлегендәге күләмдә кыскартылу һәм индексацияне исәпкә алып бюджет чараларын вакытында алу һәм куллану;

- бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары турында вакытында белдерү кәгазе алу.

Җирлек Башкарма комитеты бюджет чараларын алучы буларак хокуклы:

- вакытында бюджет гаризалары яки башка бюджет чараларын алуга хокукларны раслаучы башка документларны бирү;

- бюджет чараларын аларның максатчан билгеләнеше нигезендә нәтиҗәле куллану;

- кире кайтару нигезендә тәкъдим ителгән бюджет чараларын вакытында һәм тулы күләмдә кире кайтару;

- түләүсез нигездә тәкъдим ителгән бюджет чараларын куллану өчен түләүне вакытында һәм тулы күләмдә кертү;

- бюджет чараларын куллану турында хисапны һәм башка мәгълүматларны вакытында тәкъдим итү.

3.8. Башкарма комитет Дөбъяз авыл җирлеге исеменнән муниципаль гарантияләр бирү хокукына ия.

## 4. Җирлек Башкарма комитеты милке

4.1. Башкарма комитет милке мөстәкыйль балансга исәпкә алына һәм әлеге Нигезләмә нигезендә үз вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен кирәкле төп һәм әйләнештәге чаралардан гыйбарәт.

Мөлкәткә керәләр:

- төп фондлар (биналар, корылмалар, җиһазлар, автомобильләр һ.б.) һәм әйләнештәге чаралар, материаль кыйммәтләр һәм җирле бюджеттан төп эшчәнлеккә кертелә торган финанс ресурслар;

- иганә яки башка төр ярдәм сыйфатында, законнар нигезендә бирелгән мөлкәт.

4.2. Җирлек Башкарма комитетының муниципаль милек булып саналган мөлкәте (биналар, җиһазлар, техника, автотранспорт чаралары һ.б.) җирлек Башкарма комитетына оператив идарә итү хокукында беркетелгән.

Җирлек Башкарма комитеты милке тартып алынмый, приватизацияләнелми.

4.3. Җирлек Башкарма комитеты бинасы урнашкан җир кишәрлеге даими (сроксыз) куллануга тәкъдим ителгән. Җирдән куллану мәсьәләләре Россия Федерациясе җир законнары белән җайга салына.

4.4. Физик һәм юридик затлардан ярдәм, бирү, иганә формасында алынган милек җирлек Башкарма комитеты милкенә кертелә.

4.5. Милек белән оператив идарә итүне тормышка ашырган вакытта җирле бюджет бүлеп биргән чаралар чикләрендә җирлек Башкарма комитеты тиешле:

- беркетелгән милекне нәтиҗәле кулланырга;

- милекнең техник халәте начараюын булдырмаска, эксплуатация впроцессындагы нормаль тузудан кала;

- мөлкәткә капиталь һәм агымдагы ремонтны тормышка ашыру.

4.6. Җирлек Башкарма комитеты балансган билгеләнгән тәртиптә инвентарь һәм башка матди кыйммәтләрне исәптән чыгарырга хокуклы.

## 5. Финанслау. Авыл җирлеге Башкарма комитеты милкен исәпкә алу

5.1. Авыл җирлеге Башкарма комитетына аның алдында куелган йөкләмәләрне үтәү максатыннан билгеләнгән тәртиптә милек бүлеп бирелә.

5.2. Җирлек Башкарма комитеты аңа беркетелгән милеккә карата, билгеләнгән закон, авыл җирлеге Уставы, башка хокукый актлар, әлеге Нигезләмә нигезендә идарә итү, куллану һәм эш итүне, милекнең билгеләнеше нигезендә тормышка ашыра.

5.3. Авыл җирлеге Башкарма комитеты эшчәнлеген финанслау авыл җирлеге бюджеты чаралары хисабына тормышка ашырыла. Авыл җирлеге Башлыгы, авыл җирлеге Башкарма комитетын агымдагы карап тоту һәм эшләтүгә бүлеп бирелгән җирле бюджет чараларын төп бүлүче булып санала.

5.4. Авыл җирлеге Башкарма комитеты эшчәнлегенең нәтиҗәләре, авыл җирлеге башлыгы тарафыннан раслана торган квартал, еллык хисапларда һәм

балансларда чагылдырыла.

5.5. Авыл җирлеге Башкарма комитеты оператив, бухгалтер исәп-хисабын тормышка ашыра, статистик һәм бухгалтер хисабын алып бара, законнар белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда хисапны тәкъдим итә.

5.6. Авыл җирлеге Башкарма комитеты үзенә йөкләнгән вәкаләтләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен закон тәртибендә билгеләнгән тәртиптә җаваплылык йөртә.

## 6. Авыл җирлеге Башкарма комитетын бетерү яки үзгәртеп кору

6.1. Авыл җирлеге Башкарма комитетын берләштерү, кушу, аерып алу, үзгәртеп кору формасында бетерү яки үзгәртеп кору авыл җирлеге Советы карары яки суд карары нигезендә тормышка ашырыла.

6.2. Авыл җирлеге Советы карары яки суд карары нигезендә, авыл җирлеге башлыгы норматив хокукый акт белән бетерү комиссиясе оештыра һәм РФ Гражданнар кодексы нигезендә авыл җирлеге Башкарма комитетын бетерү һәм үзгәртеп кору срокларын һәм тәртибен билгели. Бетерү комиссиясе билгеләнгән мизгелдән авыл җирлеге Башкарма комитеты эшләре белән идарә итү вәкаләтләре аңа күчә.

6.3. Авыл җирлеге Башкарма комитетын бетерү юридик затлар өчен Бердәм дәүләт реестрына бу турыда язма кертелгәч тәмамланган булып санала.